КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2023 ел, 9 октябрь

г.Казань

№ 1271

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалану тәртибе турында» 2016 ел, 22 август, 581 нче карары белән расланган Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалануга рөхсәтнамәләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалану тәртибе турында» 2016 ел, 22 август, 581 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 1 апрель, 257 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 775 нче; 2023 ел, 10 июнь, 709 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалануга рөхсәтнамәләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә, $4^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$4^1$. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән юридик затлар, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар кергән датага Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелмәгән оешманы гамәлгә куючы (гамәлгә куючылар) белешмә языла торган датага карата салым түләүченең, салым җыючының яки салым агентының бердәм салым счетының уңай, тискәре яки нуль сальдосы турында белешмә яисә салым органы мәгълүматлары

нигезендә белешмә языла торган датага карата салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычларын үтәү турында белешмә тапшыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин